**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«26» октябрь 2022 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылында яшәүче, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Иске Татар Әмзәсе авылындагы зират территориясен төзекләндерү;

- Иске Татар Әмзәсе авылында зиратның хуҗалык инвентарен саклау өчен павильон сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина